**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

унберенче утырыш

# КАРАРЫ

30 нчы май 2021 ел **№ 64** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының 2006 елның 23 декабрендәге 72 номерлы "Теләче муниципаль районы милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 17.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 4 июнендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2006 елның 23 декабрендәге 72 номерлы "Теләче муниципаль районы милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында" карарына (Теләче муниципаль район Советының 29.10.2010 ел, № 7, 04.02.2013 ел, № 141, _ карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Теләче муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында Нигезләмәгә:

А) 1.4 пунктында «Башкарма комитет» сүзләрен төшереп калдырырга;

Б) 1.9 пунктының 10 пунктчасына үзгәреш кертергә, "шушы дәүләт яисә муниципаль контракт" сүзләреннән соң аны түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга", яисә дәүләт яисә муниципаль автоном учреждениесе белән "Юридик затларның аерым төрләре товарларын, эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен сатып алу турында" 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән конкурс яисә аукцион нәтиҗәләре буенча килешү төзелгән затка, әгәр күрсәтелгән хокукларны бирү әлеге килешүне үтәү максатларында сатып алу турындагы документларда каралган булса", "дәүләт яисә муниципаль контрактны үтәгәндә" сүзләреннән соң "яисә шартнамә" сүзләре өстәргә;

В) 1.18 пунктында «Башкарма комитетның» сүзләрен «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының» сүзләренә алмаштырырга;

Г) 2.1 пунктында «район Башкарма комитет Җитәкчесен» сүзләрен «Теләче муниципаль Районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

Д) 2.6 пунктында «Башкарма комитет Җитәкчесен» сүзләрен «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов